СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

«15» июнь 2020 ел № 50

**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советына депутатлар сайлаулары билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Уставының 13 статьясы нигезендә Яңа Кишет авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча “Арча хәбәрләре” (“Арский вестник”) район газетасында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда ТР, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты, Кышкар авылы, Яңа урам, 125 йорт, Симетбаш авылы, Үзәк урам, 19а йорты адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов